КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 21 ноябрь г.Казань № 980

Кайбер дәүләт бюджет учреждениеләре хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе», «Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсе каршындагы Кунак йорты» һәм «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет учреждениеләре хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү һәм хезмәте өчен түләүне җайга салу максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2026 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе», «Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсе каршындагы Кунак йорты» һәм «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 29 март, 194 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 27 август, 748 нче, 2021 ел, 7 декабрь, 1189 нчы, 2022 ел, 15 сентябрь, 1005 нче, 2023 ел, 9 июнь, 703 нче, 2024 ел, 29 апрель, 286 нчы, 2025 ел, 14 апрель, 225 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) билгеләнгән тәртиптә билгеләнә торган «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе», «Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсе каршындагы Кунак йорты» һәм «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет учреждениеләре (алга таба – учреждениеләр) җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттырырга.

2. Әлеге карарның 1 пункты нигезендә учреждениеләр җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләп чыгару өчен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесе белгеченең вазыйфаи окладе күләмен 1,1 тапкырга индексләштырырга һәм 16 928 сум күләмендә билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бу карарны тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә.

4. Учреждениеләр җитәкчеләренә элегрәк чыгарылган актларын әлеге карарга туры китерергә.

5. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В. Песошин